**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г. Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

**2024 елның 23 сентябре** **74-РС номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында»2021 елның 25 октябрендәге 77-РС номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019елның 29 маендагы 116-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе торак кодексына үзгәрешләр кертү турында»2019елның 2 декабрендәге 390-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карар кылды:,

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының «Татарстан Республи-касы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында»2021 елның 25 октябрендәге 77-РС номерлы карарына, түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

1) 2.5 пункт.

- «Тәртипкә карата мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында» сүзләрен «күпфатирлы йорттагы торак урынны торак булмаган бинага күчерү тәртибенә, гамәлгә ашыру тәртибенә таләпләрне бозу фактлары турында» сүзләренә алмаштырырга";

2) 2.4 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яисә күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеге буенча махсуслаштырылган башка кулланучылар кооперативы тарафыннан дәүләт торак күзәтчелеге органына күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрнамә нигезендә гамәлгә ашырыла башлады;";

2. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2016 елның 20 июнендәге 39-РС номерлы карары.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында - http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны районның җирдән файдалану, төзелеш, төзекләндерү һәм экологик иминлек мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**